МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.10.2023 Казан ш № 781

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 4 октябрендәге 781 номерлы боерыгы белән расланды

# Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

### 1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

1.1.1. Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте  (алга таба – Регламент, дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карары белән Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килү сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучылар категориясенә кертелгән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары,  чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче, ТР МК карары).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен законлы вәкилләр яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затлар тәкъдим итә ала.

1.1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

2.1.1. Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән

гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү).

## 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) башкара.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Татарстан Республикасы территориясендә мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яки шәһәр округында Министрлыкның социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) бирелә (алга таба – Идарә (бүлек)).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша үзара хезмәттәшлек турында килешү үз көченә кергән көннән башлап тапшырырга яки, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә, электрон имза белән имзаланган электрон документ (документлар җыелмасы) рәвешендә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (алга таба – Бердәм портал) аша җибәрергә мөмкин.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Бер тапкыр акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Дәүләт сервислары платформасы» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча;

шәхси кабинет аша Бердәм порталда.

Кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр телефонга смс-хәбәр итеп җибәрелергә мөмкин.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.5. Бер тапкыр акчалата түләү билгеләү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
электрон имза турында белешмәләр.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар;

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

**2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты**

2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә, шулай ук КФҮ регламентында каралган срокны исәпкә алып күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси кабинет аша Бердәм порталдан тапшырылган очракта, гаризага эш номенклатурасына һәм «Документларны тикшерү» статусына ярашлы рәвештә номер бирелгән көннән алып 15 эш көне эчендә күрсәтелә, ул Бердәм порталдагы шәхси кабинетта чагылдырыла.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән үзе тапшырылган очракта, яисә почта аша җибәрелгәндә, яисә КФҮ аша бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән карар турында Министрлык тарафыннан хәбәр карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне дәвамында, алуның сайланган ысулына ярашлы рәвештә җиткерелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресы буенча, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына;

Әгәр гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда шәхси кабинет аша тапшырылган булса, хәбәр

Министрлык тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә җибәрелә.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

### 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымтага яки әлеге Регламентка 2 нче кушымтага туры китереп, кәгазьдәге документ формасында – балигъ булмаган баланың яисә хокукка сәләтсез затның вәкиле һәм (яки) законлы вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта№

Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә – әлеге пункт таләпләренә ярашлы рәвештә имзаланган электрон формада (Бердәм порталда интерактив форманы тутыру юлы белән, нинди дә булса башка формада өстәмә гариза бирү таләп ителми);

2) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль рәвештә расланган тәрҗемәсе;

3) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән никахлашу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль рәвештә расланган тәрҗемәсе;

4) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы сәламәтлеккә килгән зыянның авырлыгы турында медицина бәяләмәсе;

5) мөрәҗәгать итүчене региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлегенә зыян алган дип тану турында тикшерүче (дознаватель) карары яки

региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлегенә зыян күргән дип тану турында суд карары (судья карары);

6) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык, әлеге Регламентның 7 нче кушымтасы нигезендә тарату өчен шәхси мәгълүмат субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслаучы документны күрсәтә, шул исәптән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында карар кабул иткәндә дә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган документны һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документның күчермәсен күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә яки 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә көчәйтелгән квалификацияле имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә;

Идарәгә (бүлеккә) шәхсән яисә почта аша кәгазьдә җибәреп;

Бердәм портал аша электрон формада, Бердәм порталдагы шәхси кабинет аша сорау формасын тутыру юлы белән.

Бердәм портал аша гариза биргәндә гариза һәм электрон документлар формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (таныкланган) булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БИАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек), күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, гариза һәм аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) яки КФҮ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Гариза шулай ук Идарәдә (бүлектә) белгеч тарафыннан шәхсән кабул ителгәндә электрон рәвештә дә тутырылырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон язуларны укый торган җайланмадан файдаланып имзалый.

2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге документлар (мәгълүматлар) алына:

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлне региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлгә кертүне раслаучы документлар. Мәгълүмат бирү турындагы сорау Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына җибәрелә;

«Россия Эчке эшләр Министрлыгының Миграция буенча мәгълүматлар витринасы» мәгълүмат системасыннан паспортның (гариза бирүче, гариза бирүченең вәкиле) чынлыгы турында;

«Россия Эчке эшләр министрлыгының Миграция буенча мәгълүматлар витринасы» мәгълүмат системасыннан шәхесне (гариза бирүче, гариза бирүченең вәкиле) раслаучы башка документ турында;

Федераль нотариаль палатадан вәкилнең вәкаләтләре турында (нотариаль формада ышаныч кәгазе);

«Витрина (Хезмәт эшчәнлеге, пенсия статусы)» Россия Социаль фондының мәгълүмат системасыннан шәхси счетның иминият номеры турында;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында. Мәгълүмат бирү турындагы сорау Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

Гражданлык хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрыннан туу турында (тууны дәүләт теркәве турында мәгълүмат), исемне үзгәртү (исемне үзгәртүне дәүләт теркәве турында мәгълүмат), никахлашу (никахлашуны дәүләт теркәве турында мәгълүмат), аерылышу (аерылышуны дәүләт теркәве турында мәгълүмат), аталыкны билгеләү (аталыкны билгеләүнең дәүләт теркәве турында мәгълүмат), үлем (гаризада күрсәтелгән затның (затларның) үлемен дәүләт теркәве турында мәгълүмат) турында (Федераль салым хезмәтеннән);

ата-ана хокукларын үзгәртү белән бәйле затлар реестрында, эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында һәм законлы вәкилләр реестрында (бала турында опека (попечительлек) билгеләү турында мәгълүмат) алар турында белешмәләр булган затлар турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

ата-ана хокукларын үзгәртү белән бәйле затлар реестрында, эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында һәм законлы вәкилләр реестрында (ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү) турында мәгълүмат) алар турында белешмәләр булган затлар турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

ата-ана хокукларын үзгәртү белән бәйле затлар реестрында, эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында һәм законлы вәкилләр реестрында (эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында тору турында мәгълүмат) алар турында белешмәләр булган затлар турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан).

мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы;

күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү;

мөрәҗәгать итүченең гариза һәм документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булган очракта;

тапшырылган документларның хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда интерактив формадагы гаризада мәҗбүри юлларны корректлы (тулы итеп) тутырмау (төгәл, тулы тутырмау яисә дөрес тутырмау);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү аның вәкаләтләренә керми торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки оешмага тапшырылган очракта;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза ТР Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүгә мөрәҗәгать итү вакыты тәмамланганнан соң (ул билгеләнгән очракта) бирелгән очракта.

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

шушы Регламентның 1.1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматларның һәм (яки) документларның тапшырылуы;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән мөрәҗәгать итүчегә мондый хәл барлыкка килүе аркасында бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүнең элегрәк билгеләнгән факты булуы;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл региональ яки муниципальара дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләргә кертелмәгән очракта.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер көн эчендә

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.3. Гаризаны Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Бердәм порталдагы шәхси кабинетта гаризаның җибәрелгән булуын

раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.11.4. Гаризаны теркәү ул кергән көнне мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы нигезендә Идарә (бүлек) тарафыннан, КФҮ мәгълүмат системасында яки электрон документ әйләнеше системасында электрон журналда гомуми эш алып бару тәртибендә башкарыла.

2.11.5. КФҮдән Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән һәм Идарәнең (бүлекнең) эш вакыты тәмамланганнан соң, ял яки эшләми торган бәйрәм көнендә алынган документларны теркәү киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килә торган беренче эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.11.6. Бердәм портал аша электрон формада җибәрелгән гаризаны Идарә (бүлек) белгече «Дәүләт сервислары платформасы» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә. Идарә (бүлек) белгече гаризаны алганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә аның гаризасын теркәү турында электрон хәбәр җибәрә.

### 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм

текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәтен күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә ярдәм күрсәтү;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

КФҮ аша электрон гариза бирү мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал аша электрон рәвештә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү (консультация бирүдән һәм гариза кабул итүдән тыш) КФҮ аркылы гамәлгә ашырылмый.

2.13.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан яки Бердәм порталдан алынырга мөмкин.

2.13.7. Комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.13.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә (бүлек), шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең яки гаризаны имзалау өчен вәкаләт бирелгән мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

2.14.4. Гариза Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленә Бердәм порталда шәхси кабинетка Идарә (бүлек) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.5. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

2.14.6. Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.7. Мөрәҗәгать итүчеләрне Идарәгә (бүлеккә) кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал (техник мөмкинлек булган очракта), Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Идарәдә (бүлектә) билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итү датасы, вакыты һәм урыны.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша яки Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

2.14.8. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.9. Гариза Бердәм портал аша җибәрелә ала.

Бердәм портал аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.

2.14.10. Гариза КФҮ аша җибәрелергә мөмкин.

2.14.11. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Бердәм портал аша (техник мөмкинлек булганда) гаризалар бирү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә башкарыла.

2.14.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.13. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Дәүләт сервислары платформасы» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## III. 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралардан (гамәлләрдән) тора:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза тутыру өлешендә дә;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү (документларны кабул итүдән баш тарту);

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталдагы шәхси кабинетта

гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, электрон почта аша, шул исәптән техник мөмкинлек булганда, Бердәм портал аша һәм (яки) Идарәгә (бүлеккә) дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен хат белән мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече шәхсән, телефон, электрон почта, Бердәм портал аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү (документларны кабул итүдән баш тарту).

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документларның күчермәләрен теркәп, Идарәгә (бүлеккә) гариза тапшыра.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) почта аша заказлы хат итеп җибәрелергә мөмкин.

Электрон рәвештә җибәрелә торган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана (таныклана) һәм Идарәгә (бүлеккә) электрон чыганаклардан файдаланып тапшырыла.

Идарәгә (бүлеккә) почта аша, электрон почта буенча, КФҮ, Бердәм портал аша алынган гариза мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителгән гариза һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карала.

Бердәм портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизацияләнә;

Бердәм порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр гаризаның электрон форма кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) Бердәм порталда кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә 3 ай дәвамында.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Идарәгә (бүлеккә) Бердәм портал аша җибәрелә.

Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Идарә (бүлек) белгече:

Бердәм порталдан килгән электрон гаризалар булуын тикшерә, тикшерү ешлыгы көненә 2 тапкырдан да сирәгрәк түгел;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече Идарә (бүлек) җитәкчесеннән имзалатып, документларны кабул итүдән баш тарту турында карарны әлеге Регламентның 3 нче кушымтасындагы форма буенча рәсмиләштерә һәм мөрәҗәгать итүчегә документларны кире кайтарып бирә.

Гариза һәм документлар почта, шул исәптән электрон почта аша алынган очракта, документлар, документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар белән берлектә, почта, шул исәптән электрон почта аша кире кайтарыла. Гаризаны Бердәм портал аша биргәндә, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның гаризаларын теркәү журналында әлеге Регламентның 4 нче кушымтасындагы форма буенча терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, алынганда беркетелгән номеры турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу бирә (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта);

гаризаны теркәү турында почта, электрон почта (документлар почта, электрон почта аша җибәрелгәндә) яки Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына (гаризаны Бердәм портал аша җибәргәндә) хәбәр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхси кабул иткәндә – гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) алынган көннән соң бер эш көне эчендә;

гариза Бердәм портал аша кергәндә – гариза һәм документлар Идарәгә (бүлеккә) кергән көнне яки, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш вакыты тәмамланганнан соң килгән очракта, – икенче эш көнендә;

гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, язу яки мөрәҗәгать итүчегә кайтарылган документлар, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документларны теркәп, кәгазьдә КФҮ тапшыра ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү.

Административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып Идарәдә (бүлектә) теркәлгән гариза һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документларны тапшырмау тора.

3.4.1. Идарәдә (бүлектә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, Идарә (бүлек) белгече әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны бирү турында гаризалар әзерли һәм аларны, шул исәптән электрон формада да, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен сорала һәм алына торган документлар (белешмәләр) исемлеге:

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлне региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлгә кертүне раслаучы документлар (белешмәләр). Мәгълүмат бирү турындагы сорау Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына җибәрелә;

«Россия Эчке эшләр Министрлыгының Миграция буенча мәгълүматлар витринасы» мәгълүмат системасыннан паспортның (гариза бирүче, гариза бирүченең вәкиле) чынлыгы турында;

шәхесне (гариза бирүчене, гариза бирүче вәкилен) раслаучы башка документ турында, «Россия Эчке эшләр министрлыгының Миграция буенча мәгълүматлар витринасы» мәгълүмат системасыннан мондый документ хуҗасының тору урыны буенча исәпкә алынуы яки яшәү урыны буенча теркәү адресы турындагы белешмәләр турында;

Федераль нотариаль палатадан вәкилнең вәкаләтләре турында (нотариаль формада ышаныч кәгазе);

«Витрина (Хезмәт эшчәнлеге, пенсия статусы)» Россия Социаль фондының мәгълүмат системасыннан шәхси счетның иминият номеры турында;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында. Мәгълүмат бирү турындагы сорау Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

Гражданлык хәле актлары язмаларының бердәм дәүләт реестрыннан туу турында (тууны дәүләт теркәве турында мәгълүмат), исемне үзгәртү (исемне үзгәртүне дәүләт теркәве турында мәгълүмат), никахлашу (никахлашуны дәүләт теркәве турында мәгълүмат), аерылышу (аерылышуны дәүләт теркәве турында мәгълүмат), аталыкны билгеләү (аталыкны билгеләүнең дәүләт теркәве турында мәгълүмат), үлем (гаризада күрсәтелгән затның (затларның) үлемен дәүләт теркәве турында мәгълүмат) турында (гариза Федераль салым хезмәтенә җибәрелә);

ата-ана хокукларын үзгәртү белән бәйле затлар реестрында, эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында һәм законлы вәкилләр реестрында (бала турында опека (попечительлек) билгеләү турында мәгълүмат) алар турында белешмәләр булган затлар турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

ата-ана хокукларын үзгәртү белән бәйле затлар реестрында, эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында һәм законлы вәкилләр реестрында (ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү) турында мәгълүмат) алар турында белешмәләр булган затлар турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

ата-ана хокукларын үзгәртү белән бәйле затлар реестрында, эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында һәм законлы вәкилләр реестрында (эшчәнлек сәләте үзгәртелгән затлар реестрында тору турында мәгълүмат) алар турында белешмәләр булган затлар турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан

электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралган белешмәләрнең булмавы турында Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән хәбәр.

3.5. Гаризаны һәм документларны Министрлыкка җибәрү

Идарә (бүлек) белгече Министрлыкка әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар белән хат проектын рәсмиләштерә һәм хат проектын Идарә (бүлек) җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Идарә (бүлек) җитәкчесе теркәлеп бара торган хатка кул куя.

Идарә (бүлек) белгече әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кушымтасы белән Идарә (бүлек) җитәкчесе имзалаган хатны Министрлыкка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Идарә (бүлек) ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан (оешмаларыннан) килгән мәгълүматларны алган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар кушымтасы белән хат.

3.6. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү

Бер мәртәбә түләнә торган акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документларны Министрлык тарафыннан Идарәдән (бүлектән) алу нигез

булып тора.

3.6.1. Министрлыкның карар проектын әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи заты (алга таба – вазифаи зат) түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендә бер мәртәбә акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проекты төзи;

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, шушы Регламентка 6 нчы кушымта нигезендә форма буенча бер мәртәбә акчалата түләү билгеләү турында карар проекты төзи;

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү турында карар кабул итү өчен җаваплы булган Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарына (алга таба – министр урынбасары) имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Министрлыкка Идарәдән (бүлектән) гариза һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документлар, Идарә (бүлек) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар (мәгълүматлар) белән хат килгән көннән алып дүрт эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты.

3.6.2. Министр урынбасары бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектына кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында имзаланган карар.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (язмача формада почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр итеп, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү турында кабул ителгән карар турында яки бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту турында хәбәр итә һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар күчермәсен Идарәгә (бүлеккә) җибәрә. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар күчермәсе мөрәҗәгать итүчегә ул күрсәткән ысул белән (почта адресына язмача формада, телефонга смс-хәбәр итеп, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына) җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү, бер тапкыр бирелә

торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарның Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән күчермәсе, бер тапкыр акчалата түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән карар күчермәсе..

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар Идарә (бүлек) тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә алынган документларда хаталар һәм (яки) ялгышлар булуы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гариза тапшыра.

3.8.2. Хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү бушлай башкарыла.

3.8.3. Документларны кабул итү һәм теркәү өчен җаваплы булган Идарә (бүлек) белгече:

хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гаризаны әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы нигезендә форма буенча Гаризаларны теркәү журналында терки;

хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гаризаны теркәп, Министрлык өчен теркәлеп бара торган хат проектын рәсмиләштерә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гаризаны теркәү көненнән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә (бүлек) җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән, теркәлеп бара торган хат проекты.

3.8.4. Идарә (бүлек) җитәкчесе теркәлеп бара торган хатка кул куя.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турындагы гариза теркәлгән, имзаланган теркәү хаты.

3.8.5. Идарә (бүлек) белгече Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан имзалаган теркәү хатын хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гаризага кушып, Министрлыкка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гаризаны кушып, Министрлыкка теркәү хатын җибәрү.

3.8.6. Документларны карау һәм хокукый бәяләү, дәүләт хезмәте күрсәтү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карарлар кабул итү өчен җаваплы булган Министрлык белгече:

хаталарны һәм (яки) ялгышларны төзәтү турында гаризаны әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы нигезендә форма буенча Гаризаларны теркәү журналында терки;

гаризада күрсәтелгән мәгълүматны тикшерә:

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын яңадан рәсмиләштерә;

министр урынбасарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарның яңадан рәсмиләштерелгән проектын имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, министр урынбасарына имзалау өчен җибәрелгән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарның яңадан рәсмиләштерелгән проекты.

3.8.7. Министр урынбасары бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм аны вазыйфаи затка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында имзаланган яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.8.8. Вазыйфаи зат гаризада күрсәтелгән ысул белән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән, яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.8.9. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында бирелгән карарда хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында язма гаризаны КФҮ бирә ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

Идарәгә (бүлеккә) техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

Күпфункцияле үзәк белгече Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

## IV. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла. Тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык бүлекләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Идарә (бүлек) белгечләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## V. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять ителергә мөмкин.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле

үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» челтәрен кулланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mtsz.tatarstan.ru) аша, Бердәм портал (https://www.gosuslugi.ru/), КФҮ рәсми сайты (http://mfc16.tatarstan.ru), «Судка кадәр шикаять итү» дәүләт мәгълүмат системасы (do.gosuslugi.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең), дәүләт хезмәтен күрсәтүче Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затының. КФү, КФҮ хезмәткәренең мөрәҗәгать

итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.6.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6.2. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.8. Шикаятьне бирү һәм карау тәртибе турында мөрәҗәгать итүчеләргә мәгълүмат бирү мәгълүматны дәүләт хезмәте күрсәтелгән урыннарда, Бердәм порталда (gosuslugi.ru), Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru), КФҮ рәсми сайтында (http://mfc16.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, телефон, электрон почта аша, шәхси кабул итү вакытында гамәлгә ашырыла.

Региональ һәм муниципальара
дәрәҗәдәге табигый һәм техноген
характердагы гадәттән тыш хәл
нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян
килгән гражданнарга бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләү билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасының ______________________ Социаль яклау идарәсе
(муниципаль район яки шәһәр округы)
(бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

_____________________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Паспорт_______________________________________
Кем тарафыннан бирелгән ___________________
Бирелгән датасы ____________________________
Яшәү урыны адресы___________________

_____________________________________________
Туу датасы _____________________
Туу урыны ________________________
Телефон ________________________________
Вәкилнең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта) __________________

_____________________________________________
Паспорт ________________________________________
Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ турында мәгълүмат, шул исәптән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче ___________________________
Даими яшәү урыны адресы __________________

_____________________________________________
Телефон __________________________________

ГАРИЗА

Билгеләвегезне сорыйм ______________________________________________,
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
_____________________________________________________________________________,
(туу датасы, шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары, яшәү урыны адресы)

региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә сәламәтлеккә зыян килүгә бәйле рәвештә сәламәтлеккә зыян алган гражданин

(сәламәтлеккә зыянның авырлык дәрәҗәсе, сәламәтлеккә зыянның авырлыгы турында медицина бәяләмәсе реквизитлары (номеры, бирелгән датасы, медицина учреждениесе исеме) күрсәтелә)

Татарстан Республикасы территориясендә региональ һәм муниципальара
дәрәжәдәге табигый һәм техноген характе

________________________________________(Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме)

______________________________________________________________________________,
(тикшерүченең (дознавательнең алучының, судьяның) карары реквизитлары яисә гражданинны региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күрүче дип тану турындагы суд карары, сәламәтлеккә зыян күрү дәрәҗәсен күрсәтергә)

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне кредит оешмасына күчерүне сорыйм: ______________________________________________________________
(кредит оешмасы исеме)

Түләү өчен банк реквизитлары:
Шәхси счет: ________________________________________
Исәп-хисап счеты: ______________________________________
Банкның исеме: ________________________________
БИК _______________________________________________
Салым түләүченең тәңгәллек номеры___________________________________
Исәпкә алу сәбәбе коды (КПП): ______________________________
Банк картасы номеры ____________________________

Мөрәҗәгать итүченең элемтәгә керү белешмәләре:
Телефон: ___________________________________________

Мөрәҗәгать итүче:________________________________ ________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имзасы) (дата)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:
почта адресы буенча язма формада: ________________________
______________________________________________________________________________;
(почта адресы күрсәтелә)
бәлеге телефонга смс-хәбәр итеп: ____________________________________;
(телефон номеры күрсәтелә)
электрон почта адресы буенча электрон документ формасында:
______________________________________________________________________________,
(электрон почта адресы күрсәтелә)

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында шәхси кабинет аша: ___________________________________.
(«әйе» дип күрсәтелә яки сызык куела»)

Мөрәҗәгать итүче:________________________________ ________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имзасы) (дата)

Белгеч:

---
[1] (кирәклесе астына сызарга);

_________________________________ ____________ «___» ______ 20__ ел.
(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)) (имза) (дата)

Язу-хәбәрне алдым ________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

___________________________________________________________________________
Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №___ Документлар саны ___ берәмлек, _____ биттә.
Документларны кабул итте __________ ________ ____________ ______20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасының ________________________ Социаль яклау
(муниципаль район яки шәһәр округы)
идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

___________________________________
(фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))
Паспорт______________________________
Кем тарафыннан бирелгән __________________
Бирелгән датасы __________________________
Яшәү урыны адресы_____________________

______________________________________
Туу датасы __________________
Туу урыны ______________________
Телефон ______________________________
Вәкилнең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта) ________________

______________________________________
Паспорт _______________________________
Вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ турында мәгълүмат, шул исәптән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче ____________________________
Даими яшәү урыны адресы _______________

______________________________________
Телефон _____________________________

ГАРИЗА

Мин, балигъ булмаган яки хокукка сәләтсез кешенең вәкиле (законлы вәкиле)
_____________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), баш килештә,
_____________________________________________________________
туган көне, шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары, яшәү урыны адресы,

_______________________________________________________________________________
законлы вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ белешмәләре)

бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләүне сорыйм:
минем балигъ булмаган балам ___________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) - юнәлеш килешендә,

туган көне, туу турында таныклыгы (сериясе, номеры, датасы), туу турында актның язу датасы һәм номеры яки чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән туу турында документның реквизитлары,

_______________________________________________________________________________.

Әлеге территориядә региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә: Татарстан Республикасының _________________________________________________,
(муниципаль район, шәһәр округы атамасы)

сәламәтлеккә зыян ____________________________________________________________
(сәламәтлеккә зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтергә)

_______________________________________________________________________________
(тикшерүче (дознаватель, судья) карарының реквизитларын яки гражданинны гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлегенә зыян күргән дип тану турында суд билгеләмәсен, сәламәтлеккә зыян китерүнең авырлыгы турында медицина бәяләмәсе реквизитларын (номерын, бирелгән датасын, медицина учреждениесе исемен) күрсәтергә);

_______________________________________________________________________________.
_______________________________________________________________________________.
мин аның вәкиле һәм (яки) законлы вәкиле булып торган башка затка: _______________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, шәхесне раслаучы документ мәгълүматлары)

әлеге территориядә региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә: Татарстан Республикасының _________________________________________________,
(муниципаль район, шәһәр округы атамасы)

сәламәтлеккә зыян ____________________________________________________________
(сәламәтлеккә зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтергә)

_______________________________________________________________________________.
(тикшерүче (дознаватель, судья) карарының реквизитларын яки гражданинны гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлегенә зыян күргән дип тану турында суд билгеләмәсен, сәламәтлеккә зыян китерүнең авырлыгы турында медицина бәяләмәсе реквизитларын (номерын, бирелгән датасын, медицина учреждениесе исемен), сәламәтлеккә зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтергә);

_______________________________________________________________________________.
_______________________________________________________________________________.
_______________________________________________________________________________.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне кредит оешмасына күчерүне сорыйм: _________________________________________________________
(кредит оешмасы исеме)

Түләү өчен банк реквизитлары:
Шәхси счет: _____________________________________
Исәп-хисап счеты: ___________________________________
Банкның исеме: ______________________________

БИК ___________________________________________
Салым түләүченең тәңгәллек номеры________________________________
Исәпкә алу сәбәбе коды (КПП): ____________________________
Банк картасы номеры __________________________
Мөрәҗәгать итүченең элемтәгә керү белешмәләре:
Телефон: _______________________________________

Мөрәҗәгать итүче:_____________________ _________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имзасы) (дата)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:
почта адресы буенча язма формада: ______________________
_____________________________________________________________________;
(почта адресы күрсәтелә)
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп: ________________________________________;
(телефон номеры күрсәтелә)
электрон почта адресы буенча электрон документ формасында
_____________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында шәхси кабинет аша: _________________________________.
(«әйе» дип күрсәтелә яки сызык куела»)

Мөрәҗәгать итүче:_______________________ _________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (имзасы) (дата)

Белгеч:
________________________________ ____________ «___»_______ 20__ ел.
(вазыйфа, Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)) (имза) (дата)
Язу-хәбәрне алдым ___________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
_________________________________________________________________
Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры _________________ Документлар саны ____ данә, __ биттә.

Документларны кабул итте ___________ _________ ________«___» ____ 20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

_______________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме күрсәтелә)

Документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

«________________» № «____»

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлегенә зыян алган гражданинга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүгә гаризаны һәм аңа теркәлгән кушылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге нигезләр буенча гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

___________________________________________________________________________

(гариза һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр күрсәтелә)

Сез әлеге хокук бозуларны бетергәннән соң кабат гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тарту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына шикаять җибәрү юлы белән судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять ителергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы

______________________________________________________

(Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) исеме күрсәтелә)

___________________________________ _____________ «___» _______ 20__ ел.

(имза) (тулы имза) (дата)

Карар проектын әзерләгән зат:

__________________ _____________ _________________________________________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Мөһер урыны

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

Гражданнарның гаризаларын теркәү журналы

| № т/с | Мөрәҗә-гать итү датасы | Мөрәҗәгать номеры | Гражданин-ның ФИА | Адрес | Мөрәҗә-гать итү сәбәпләре | Мөрәҗә-гать итү нәтиҗәләре | Сәбәпләрен күрсәтмичә, мөрәҗәгать итү нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Региональ һәм муниципальара
дәрәҗәдәге табигый һәм техноген
характердагы гадәттән тыш хәл
нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян
килгән гражданнарга бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләү
билгеләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 5 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләүдән баш тарту турында карар
«_____________» № «____»

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән һәм сәламәтлегенә зыян алган гражданинга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүгә «___________» № «___» гаризаны һәм аңа теркәлгән кушылган документларны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге нигезләр буенча бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

________________________________________________________________________

(бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүдән баш тарту өчен нигезләр күрсәтелә)

________________________________________________________________________

Бу баш тарту суд тәртибендә шикаять ителергә мөмкин.

Министр урынбасары_______________ ________________________

(имза) (тулы имза)

Карар проектын әзерләгән зат _____________ ________________________

(имза) (тулы имза)

Мөһер урыны

Региональ һәм муниципальара
дәрәҗәдәге табигый һәм
техноген характердагы
гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә
сәламәтлегенә зыян килгән
гражданнарга бер тапкыр
бирелә торган акчалата түләү
билгеләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 6 нчы кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгы

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү турында карар
«_____________» № «____»

«__________» № «_____» гаризаны һәм аңа кушылган документларны карау нәтиҗәсендә, региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә табигый һәм техноген характердагы сәламәтлеккә зыян күргән гражданинга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү турында карар кабул ителде

| Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) | Сәламәтлеккә зыянның авырлык дәрәҗәсе | Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|---|
| | | |

Министр урынбасары_______________ ______________________
(имза) (тулы имза)

Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге җитәкчесе ________________________
(имза) (тулы имза)

Карар проектын әзерләгән зат _____________ __________________
(имза) (тулы имза)

Мөһер урыны

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (Идарәсе) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

Персональ белешмәләрне эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин,

______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

Теркәлгән адрес ____________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

паспорт сериясе _______ № ________________ бирелгән ________________________
(дата)

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________,
(кем тарафыннан бирелгән)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясы нигезендә, ______________________________ адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасының ____________________________ Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (идарәсе) йөзендә, Татарстан Республикасы, Казан ш., Волгоград ур., 47 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ризалык бирәм:
(Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы)

_________________________________________________________________,
(почта адресы күрсәтелә)

региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

максатларында минем түбәндәге шәхси белешмәләремә карата аларны эшкәртү өчен (автоматлаштыру чараларын кулланып яки андый чараларны кулланмыйча, җыю, яздыру, системалаштыру, туплау, саклау, тәгаенләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү), шәхси билгеләрен бетерү, файдалана алмаслык итү, бетерү, юкка чыгаруны да кертеп, гамәл (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасын башкарырга:

- фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), шул исәптән, үзгәртелгән очракта, алдагы фамилияләр, исемнәр һәм (яки) ата исемнәре;
- телефон номеры, электрон почта адресы яки почта адресы;
- яшәү урыны буенча теркәлү адресы (булган урыны), чынлыкта яшәү адресы;
- паспорт белешмәләре (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);
- бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен эшкәртү кирәк булган башка шәхси мәгълүматлар.

Мин танышып чыктым:

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүне имзалаганнан соң, мин тапшырган документларны саклау срогы чykканчыга кадәр гамәлдә була;
- шәхси белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (Идарәсе)

_______________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2 - 11 пунктларында, 10 статьясының 2өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булган очракта, шәхси мәгълүматларны эшкәртү дәвам иттерергә хокуклы;

- өченче затларга карата тапшылыра торган персональ белешмәләр бары тик Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасының ________________
(Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы)

социаль яклау бүлеге (идарәсе) аша аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында гына эшкәртеләчәк.

«_______» __________ 20__ ел. ______________/______________________________
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (Идарәсе) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

Шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,

______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

теркәлгән адрес ________________________________________________

____________________________________________________________________

_______________________________________________________________паспо рт сериясе ________ №___________ бирелгән _________________________________

(дата)

_________________________________________________________________________,

(кем тарафыннан бирелгән)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасының ____________________________ Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (Идарәсе) йөзендә, Татарстан Республикасы, Казан ш., Волгоград ур., 47 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ризалыгымны бирәм:

(Татарстан Республикасы муниципаль районы яки шәһәр округы)

урнашкан адресы: ______________________________________

(почта адресы күрсәтелә)

Региональ һәм муниципальара дәрәҗәдәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлегенә зыян килгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү максатында үземнең шәхси мәгълүматларымны таратуга (тапшыруга, бирүгә).

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге:

- фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта), шул исәптән, үзгәртелгән очракта, алдагы фамилияләр, исемнәр һәм (яки) ата исемнәре;

- телефон номеры, электрон почта адресы яки почта адресы;

- яшәү урыны буенча теркәлү адресы (булган урыны), чынлыкта яшәү адресы;

- паспорт белешмәләре (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән);

- бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен эшкәртү кирәк булган башка шәхси мәгълүматлар.

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан язма рәвештә кире алганчыга кадәр гамәлдә була.

Мин танышып чыктым:

- шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүне имзалаганнан соң, мин тапшырган документларны саклау срогы чыкканчыга кадәр гамәлдә була;

- шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;

- Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (Идарәсе), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2 - 11 пунктларында, 10 статьясының 2 өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булган очракта, шәхси белешмәләрне эшкәртүне дәвам иттерергә хокуклы;

- өченче затларга карата бирелә торган шәхси мәгълүматлар Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләнгән вәкаләтләр нигезендә генә эшкәртелә ала Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (Идарәсе) йөзендә.

«_______» __________ 20__ ел. ______________/______________________________
(имза) (тулы имза)